Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль белем бирү учреждениесе «Саклау-Баш урта гомуми белем бирү мәктәбе»

# * Тема: Төрләндергеч кушымчалар

Төзеде:Г.Ф.Талипова
Башлангыч сыйныф укытучысы

”Тел дигән дәрья бар,
Төбендә энҗе-мәрҗән бар.
Белгәннәр чумып алыр,
Белмәгәннәр коры калыр.”



***Саннар кырында хәрефләр бирелгән.***
***Саннарны үсә бару тәртибендә куйсагыз,дәреснең темасы килеп чыгар.***

7 Д

12 Ч

3 р

8 е

4 л

1 Т

11 е

10 г

6 Н

5 ә

9 р

2 ө

. . . . . . . ? . . . . . . кушымчалар.

***Саннар кырында хәрефләр бирелгән.***
***Саннарны үсә бару тәртибендә куйсагыз,дәреснең темасы килеп чыгар.***

7 Д

12 Ч

3 р

8 е

4 л

1 Т

11 е

10 г

6 Н

5 ә

9 р

2 ө

**Төрләндергеч кушымчалар.**

# *Тема: Төрләндергеч кушымчалар*

***Сүзләр тамыр һәм кушымчаларга таркала.***

***Тамыр- ул сүзнең төп мәгънәсен белдерә ,мәгънәле кисәкләргә таркалмый.***

***Кушымча- сүзнең мәгънәсен  яки формасын үзгәртә,аерым кулланылмый.***

# *Ясалышы ягыннан сүзләр тамыр сүзләр һәм ясалма сүзләр була*

***авыл*** ***авылдаш***

*авыл-тамыр сүз;* *авылдаш-ясалма сүз.*

*Ясалма сүзләр тамыр + сүз ясагыч кушымчадан ясала.*

*Авыл (тамыр)+ даш (сүз ясагыч кушымча)*

# *Кушымчаларның төрләре.*

**Сүз ясагыч кушымчалар**

-чы/че; -лык/-лек;
-даш/-дәш; -таш/-тәш;
-гыч/геч; -кы/-ке;
-гы/-ге; -кы/-ке;
-сыз/-сез; -лы/-ле;
-ла/-лә, һ.б.

авылдаш

**Сүз төрләндергеч кушымчалар**

-лар/-ләр; - нар/-нәр;
-кай/-кәй; -чык/-чек;
-сыл/-сел; -рак/рәк;
-ынчы/-енче;
-га/гә; -ка/кә;
-ар/-әр, һ.б.

авыл лар

# *Кушымчаларның тамгалары .*



- сүз ясагыч кушымчалар.



-сүз төрләндергеч кушымчалар

Бер тамырга берьюлы берничә кушымча ялганырга мөмкин:

авыл+даш+лар+ым+ны

И.Х.Мияссарова ,К.Ф.Фәйзрахманова дәреслегендә 47 нче бит,төрләндергеч кушымчалар кагыйдәсен укы.

# *1 нче бирем.*
# *Бирелгән сүзләр арасыннан ясагыч кушымчалы сүзләрне генә язып алырга.*

- ***Белем, биеклек,умарта, ташкүмер, дус, урын-җир, умартачылык, ташбака, җырчы, көн-төн, яшелчә.***

- Төрләндергеч кушымчалар бер үк сүзнең төрле формаларын барлыкка китерә.

- алма+лар → алмалар

# *2 нче бирем*

* И.Х.Мияссарова ,К.Ф.Фәйзрахманова дәреслегендә 46 нчы бит,77 нче күнегүне эшләргә.

-нокталар урынына тиешле кушымчаларны куеп, шигырьне укы. Шигырь нәрсә турында?

-нокталар урынына нинди кушымчалар өстәдең? Бу сүзләрнең тамырын тап.

# Өй эше

*1.Экранда күрсәтелгән сүзләрне сүз төзелеше ягыннан тикшерү.*

Хайваннар, кошчылык, көнгә, җырчылар, ачкыч.

*2. Шушы сүзләрне кертеп җөмләләр язу.*

*3.Төрләндергеч кушымчалар булган 6 сүз язу.*